**Фәнни-табигый эшчәнлек “Тылсымлы су”**

(4-6 яшьлек балалар өчен)

*Михайлова Р.И.,*

*66 нчы “Күңелле ноталар” балалар бакчасы,*

*Яр Чаллы шәһәре*

**Педагогик яктан кулланышы, актуальлеге, яңалыгы**.

Бала тууының беренче көненнән алып үзен әйләндереп алган дөньяны ача һәм өйрәнә. Әйләнә-тирә белән аралашу һәм аның белән элемтәгә керү, яңадан- яңа максатлар куеп аларга ирешү кешенең иң яхшы сыйфатлары.*“Сөйлә - мин онытырмын, күрсәт - мин истә калдырырмын, үземә эшләтсәң - мин аңлармын”*- ди халык мәкале. Димәк, балалар үз күзләре белән күргән һәм тотып караган әйберләрне генә ныклап исләрендә калдыралар. Мәктәпкәчә яштәге балаларның яңа кичерешләргә, экспериментларга омтылу, яңа мәгълүмәтләр эзләү балаларның үз – үзләрен тотышының гадәти күренеше. Предметларны җентекләп өйрәнү, ачу, эзләү балалар өчен мавыктыргыч бер адым булып тора.

“*Сабырлык һәм тырышлык белән алынган белем, хәтер белән бирелгән белемгә караганда ныклырак”*дип яза Л.Н.Толстой.

Шуңа күрә, тәҗрибә, күзәтү эшчәнлеге балалар бакчасында ныклы урын ала. Ул балалар һәм олылар өчен бик кызыклы һәм мавыктыргыч күренеш. Бала тәҗрибәләр, эзләнүләр вакытында яңадан- яңа белемнәргә омтыла, иҗади фикерләргә, нинди дә булса проблеманы чишәргә, уйланырга, төрлечә фикер йөртеп карарга һәм үз чиратында мөстәкыль үсеш юлына басырга тиеш. Без моны балаларның төрле эшчәнлегендә куллана алабыз.

**I. Танып белү эшчәнлеген оештыру**

Балаларга өйрәнелә торган объект турында һәръяктан тулырак мәгълүмәт бирергә, аның башка объектлар һәм әйләнә-тирәлек белән бәйләнешен күбрәк ачыкларга мөмкинлек бирә. Тәҗрибәләр, күзәтүләр

вакытында балаларның хәтере байый, уйлау һәм фикер йөртү процесслары активлаша, анализ-синтез, чагыштыру, төркемләү, күмәк эшләү сыйфаты яхшыра. Балалар үзләре күргәнне, ясаганны һәм иҗат иткәнне схемалы рәвештә күрсәтергә, сөйләргә һәм нәтиҗә ясарга өйрәнәләр. Менә нәкъ шушы сыйфатлар баланың киләчәк тормышында бик мөһим урын алып торачаклар. Яңалыкка омтылу, күбрәк белергә тырышу, эзләнүчәнлелек, аралашучанлылык – уңышлы шәхеснең төп күрсәткечләре.

Максат: эксперименталь эшчәнлек аша эзләнүчән, кызыксынучан, иҗади шәхес тәрбияләү.

Бурычлар:

1) табигый-фәнни һәм экологик белемнәрне киңәйтү, эзлеклелекне тәэмин итү;

2) алынган белемнәрне тормышта кулланырга өйрәтү;

3) гади тәҗрибәләр аша дөрес нәтиҗәләр ясарга, эзләп табу мәсьәләләрен чишәргә өйрәтү;

4) кызыксыну, иҗат итү, күзаллау һәм уйлап табу сыйфатларын тәрбияләү.

***Эксперименталь эшчәнлекне оештыру өчен:*** балаларның танып-белүен үстерүгә юнәлтелгән эшчәнлекне олы кеше белән баланың партнерлык эшчәнлеге шартларында оештырсак күпкә җиңелрәк була. Мондый белем бирү эшчәнлеге вакытында, тәрбияче бала белән бер дәрәҗәдә катнаша, балалар эшчәнлеккә үзләре теләп тартылалар, моның өчен белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге бала өчен кызыклы, үзенә тартып тора торган булырга тиеш. Белем бирү эшчәнлегенә оештыру барышында тәрбияче балаларны эшчәнлеккә мәҗбүр итми, ә кызыксындыра.

***Белем бирү эшчәнлегенең структурасы.***

1. Эзләнү бурычын кую яки проблемалы ситуация тудыру.

2. Проблеманы чишү буенча идеяләрне, гипотезаларны, чишү юллары һәм ысуллары турында үзарә сөйләшү, киңәшләшү.

3. Эксперимент үткәргәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшерү.

4. Тикшерү планыны ачыклау.

5. Кирәкле җиһазларны һәм материалларны сайлап алу, аларны тикшерү почмагына мөстәкыйль урнаштыру.

6.Төремнәргә бүлү, төркемне җитәкләүче баланы билгеләү.

7. Гипотезаларны тикшерү, күзәтү, нәтиҗәләрне билгеләү, альбомга теркәү, схемаларын ясау.

8. Нәтиҗәләр турында сөйләшү, йомгак ясау.

9. Экспериментны, эзләнү эшчәнлеген өйдә яки мөстәкыйль эшчәнлек вакытында тормышка ашыру өчен материаллар туплау.

**II. Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге.**

Тәрбияче белән бергә үткәрелгән белем бирү эшчәнлеге балага мөстәкыйль эзләнү яки эксперимент эшчәнлеге үткәрү өчен импульс, этәргеч бирергә тиеш. Тәрбияче мөстәкыйль эшчәнлек өчен шартларын тудырырга тиеш. Теләге булган балалар су, туфрак, ком белән экспериментлар үткәрәләр, яшелчә бакчасы почмагында үсемлекләр белән тәҗрибәләр уздыралар, үсемлекләрнең үсешен күзәтәләр.Әгәр бала үзе мөстәкыйль эзләнү эшчәнлеге үткәрсә, бу баланың танып-белү активлыгы, иҗади сәләте югары булуын дәлилли. Эксперимент вакытында алган белемнәрен балалар дидактик уеннарда, иҗади сәнгать эшчәнлегендә ныгыталар.

**Су белән тәҗрибәләр**

| | ***Аталышы*** | ***Барышы*** | ***Нәтиҗә*** |
|---|---|---|---|
| | ***Суның үтә күренмәле булуын ачыклау.*** | Ике стакан бирелә, берсендә су, икенчесендә сөт. Стаканнар эченә таш салына. Балаларга сорау бирелә “Кайсы савытта таш күрәсез?”, “Ни өчен дип уйлыйсыз?” | Су үтә күренмәле, чөнки аның аша әйберләр күреп була. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | ***Судан үз-үзеңне күрү*** | Өстәлгә таз белән су куела. Балаларга таз эчене карарга тәгъдим ителә һәм сорау бирелә “Нәрсә күрәсез? Үзеңне тагын кайдан күреп була?” | Суда үзеңне күреп була. |
| | ***Суның төрле халәте.*** | Балаларга стаканга салып су бирелә һәм стаканны авыштырабыз, су ага башлый. Сораулар: “Су нәрсә эшли?”, “Ни өчен дип уйлыйсыз?”<br>Балаларга кулларына боз бирелә. Сораулар: “Бу нәрсә?”. Нинди? Нәрсә эшли? Аның турында нәрсә әйтеп була?<br>Термос күрсәтелә. Сораулар: “ Бу нәрсә? Нәрсә өчен кирәк?” Капкачын ачабыз, пар чыга. Нәрсә күрәсез? Термос яныны көзге китерәм. Сорау: “Көзге өстендә нәрсә күренә?”, “ Ул кайдан барлыкка килгән?” | Су ага, чөнки ул сыеклык.<br>Боз ул катырылган су. Җылыткач суга әйләнә.<br>Нык җылыткач су газ формасына керә. |
| | ***Су төсен үзгәртү*** | Балалар алдына 3 стакан куела. Берсендә сөт. Сорау “Су нинди төстә?”, “ Сөт нинди төстә?” Буяулар бирелә. Буяуларны су эченә салып болгатабыз. Сорау “Су нишләде?”, “Ни өчен дип уйлыйсыз?” | Суның төсе юк. Суны буяп була. |
| | ***Суның тәмен*** | Өч савытка су салабыз, эчеп | Суның тәме юк. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ***билгеләү*** | карыйбыз. Беренче савытка тоз, ә икенчесенә шикәр салабыз һәм эчеп карыйбыз. Сорау: “Суның тәме бармы?”, “Ни өчен суга тәм керде?” | Су эченә салынган әйбернең тәмен ала |